## Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Советы

## КАРАР

29.01. 2015 ел, № 5

Яңа Имән авыл җирлеге территориясендә гражданнарнын үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел. № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы 1 пункты, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә турында" Яңа Имән авыл җирлеге башкарма комитетының 12.01.2015 ел карары нигезендә Яңа Имән авыл җирлеге Уставының 11,12 № 1» референдум үткәрү инициативасы турында«, Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге Советының 12.01.2015 ел, № 1» референдум үткәрү инициативасы турында " гы карарлары, Яңа Имән авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Яңа Имән авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2015 елның 15 мартына җирле референдумны билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне раслау:

"Яңа Имән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

-көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю һәм чыгаруны оештыру;
-җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
-җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерү, урамнар атамалары һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр кую, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тотуны да кертеп);
-авыл эчендәге юлларны чистартып тору
-халыкның ял итуен оештыру

«РИЗА» «ЮК».

3. Кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларына һәм авыл җирлегенең рәсми сайтына урнаштырып, әлеге карарны игълан итәргә.

4. Бу карар бастырылган көннән үз көченә керә.

Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы Вахитов И.М.Вахитов